ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 490-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Л.Р. Кадермәтова, А.И. Җиһаншин, Р.Ә. Сөләйманов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 490-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2207-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев,
Л.Р. Кадермәтова,
А.И. Жиһаншин,
Р.Ә. Сөләйманов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш); № 48 (I өлеш); № 56 (I өлеш)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «хуҗалык» сүзен «икътисадый (хуҗалык)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяда:
а) 1 өлештә:
түбәндәге эчтәлекле яңа утыз тугызынчы һәм кырыгынчы абзацлар өстәргә:
«каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү шартнамәләре буенча исәп-хисаплар максатларында каты коммуналь калдыкларның күләмен һәм (яисә) авырлыгын исәпләү ысулын билгеләү, региональ оператор һәм (яисә) каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтен кулланучы тарафыннан каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү шартнамәләре буенча исәп-хисаплар максатларында каты коммуналь калдыкларның күләмен һәм (яисә) авырлыгын исәпләү ысулын сайлау тәртибен раслау;
әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау;»;
түбәндәге эчтәлекле кырык беренче абзац өстәргә:
«әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне оештыру;»;
утыз тугызынчы абзацны кырык икенче абзац дип санарга һәм анда «әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләү, һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү эшләрен оештыру» сүзләрен «әйләнә-тирә

мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне оештыру» сүзләренә алмаштырырга;

кырыгынчы абзацны кырык өченче абзац дип санарга;

б) 2 өлештә «кырыгынчы» сүзен «кырык өченче» сүзләренә алмаштырырга;

3) 96 статьяның 1 өлешендә «башка эшләр» сүзләреннән соң «су турындагы законнар,» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 449-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясенең берничә закон актына әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау, тикшерү һәм бәяләү, мондый зыянны гавами мөлкәткә керә торган яисә хуҗасыз булган объектларга карата бетерү мәсьәләләрен җайга салуга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде.

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законга кертелгән үзгәрешләр белән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының әйләнә-тирә мохитне саклауга бәйле мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтләр исемлеге әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне оештыру вәкаләтләре белән тулыландырылды.

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» һәм «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 3 статьясындагы 3 өлешенең үз көчен югалтуын тану турында» Федераль законга һәм «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 449-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелде, алар Россия Федерациясе субъектларының җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге вәкаләтләр исемлеген каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү шартнамәләре буенча исәп-хисаплар максатларында каты коммуналь калдыкларның күләмен һәм (яисә) авырлыгын исәпләү ысулын билгеләү, региональ оператор һәм (яисә) каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтен кулланучы тарафыннан каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү шартнамәләре буенча исәп-хисаплар максатларында каты коммуналь калдыкларның күләмен һәм (яисә) авырлыгын исәпләү ысулын сайлау тәртибен раслау вәкаләте белән тулыландыра.

Закон проекты белән федераль законнардагы бу үзгәрешләрне Татарстан Республикасы Экология кодексында да чагылдыру тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы башка законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарны таләп итми.